
АПРЕЛЬ/2020/№



# Иҗади сәхифә

**Сәхифәне оештыручылар:** 3 нче урта мәктәп укучылары,татар теле һәм әдәбияты

## ТАССРга 100 ел

## *Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын…*

Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле, тик
үкенечкә калмасын.
Киң күңелле бул эчеңнән,
мыскыл ишетсәң, «вак»
диген,
Таптасыннар, хурласыннар,
тик җаның хурланмасын.
Габдулла Тукай


ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУГАН КӨНЕ ЕЛ САЕН ЯЗНЫҢ ИҢ МАТУР ВАКЫТЫНДА — 26 АПРЕЛЬДӘ БИЛГЕЛӘНЕП ҮТЕЛӘ. БУ БӘЙРӘМ ЯКЫНЛАШКАН САЕН, ВАКЫТ БЕЗНЕ 1913 ЕЛНЫҢ АПРЕЛЬ КӨННӘРЕННӘН ЕРАКЛАШТЫРГАН САЕН, ТУКАЙ БЕЗГӘ ТАГЫН ДА ЯКЫНАЯ, АНЫҢ ШӘХЕСЕ, ТАРИХТАГЫ УРЫНЫ БЕЗГӘ ТАГЫН ДА ОЛЫРАК

***В. Г. Белинскийның бик гыйбрәтле мәгълүм сүзләре бар:***
«Һәр яңа чор бөек язучы турында үз фикерен әйтә, аны үзенчә ача, аның яңа дөнья, аңа чынбарлык белән бәйләнгән яңадан-яңа сыйфатларын таба». Тукай белән дә шулай. Бөек рус тәнкыйтьчесенең сүзләрен дәвам итеп әйткәндә, Тукай, «үлем белән төгәлләнә торган ноктада тукталып калмыйча, җәмгать аңында үсеш-үзгәрешен дәвам итә торган, мәңге яши һәм алга бара торган күренешләр җөмләсенә керә».


*Менә ни өчен Тукайның юбилейларын үткәрү, Тукайны искә алу бәйрәме — бер татар халкының гына түгел, бөтен тугандаш халыкларның культура, әдәбият бәйрәменә, Ватаныбызның бөек улына халыкның тирән ихтирамын, мәхәббәтен чагылдыра торган бәйрәмгә әйләнде.*




**Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов 2020 елны Татарстан Республикасында ТАССР төзелүнең 100 еллыгы елы дип игълан итте. Бу хактагы Указга 2019 елның 25 сентябрендә кул куелган. Республиканы торгызуның һәм үстерүнең мөһим тарихи этабына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатында чараларны әзерләү һәм уздыру оештыру комитетына йөкләнгән. ТАССР 1920 елның маенда оеша.**



Татарстан- минем республикам,
Россиянең матур җирендә.
Халкым аңа үзе исем кушкан-
Бәхет теләп гомер- гомергә







АБДУЛЛАЕВА ӘДИЛӘ,4 НЧЕ А СЫЙНЫФЫ

ӘХТӘМОВА ЛАНДЫШ,,4 НЧЕ А СЫЙНЫФЫ

ГАЙНЕТДИНОВА ИЛЬВИНА,,6 НЧЫ А СЫЙНЫФЫ



ГАЛИЕВ РАМИС,6 НЧЫ А СЫЙНЫФЫ

# ТУКАЙ ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ КУНАКТА





ГАЙНЕТДИНОВА ИЛЬВИНА,6 НЧЫ А СЫЙНЫФЫ

АБДУЛЛАЕВА ӘДИЛӘ,4 НЧЕ А СЫЙНЫФЫ





ГАЙНЕТДИНОВА ИЛЬВИНА,6 НЧЫ А СЫЙНЫФЫ

АБДУЛЛАЕВА ӘДИЛӘ,4 НЧЕ А СЫЙНЫФЫ



Әхтәмова Ландыш, 4 нче А сыйныфы

# ВИКТОРИНА

***“ Шигъри тукталыш”***

1. “И туган тел, и матур тел,

Әткәм- әнкәмнең теле”

2.”Әйтсәм әйтим, син белеп кал
Чын исемем- Былтыр минем...   :

3.Әйдәле Акбай, өйрән син, арт аягың белән тор.

4. “И сабыйлар, эшләгез сез,  иң мөкатдәс нәрсә эш

5.” Мин качамын- ул куадыр, ул куадыр, мин качам”

6.Чоландагы ак майга,
Иялэшкән күселәр.
Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигә.

***“Зирәкләр һәм тапкырлар”***

1. Татарстанның нефть чыгару үзәге.
2. Буа һәм Норлатта җитештерелә торган азык- төлек.
3. Нинди шәһәр балык исемен йөртә?
4. Безнең республикада нинди авыр йөк автомобиле җитештерелә?
5. Казан Кремлендә нинди манара бар?
6. Татарстан флагында төсләрне атагыз

***“Милли үзенчәлекләр”***

1. Мөселманнарның изге китабы.
2. Татарстанның дәүләт телләре.
3. Татар халкының милли бәйрәмнәре.
4. Татар халкының милли киемнәре.
5. Татар халык ашлары
6. 30 август- нинди бәйрәм?

А.Татар һәм рус телләре
Ә.Татарстан республикасы көне,
Б.калфак, түбәтәй, читек, камзул
В.Коръән
Г.(Сабантуй, Нәүрүз, Каз өмәсе, Карга боткасы, Сөмбелә)
Д. (Өчпочмак, чәк- чәк, гөбәдия, бавырсак, бәлеш)

| А | Ә | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

## *“Беркем дә онытылмады,*
## *бернәрсә дә онытылмады”*



Бөек Ватан сугышы беткәнгә нәкъ .75 ел. Ә сугыш үзенең ачлыгы-ялангачлыгы, мәрхәмәтсезлеге һәм үлем ачысы белән 1941 елның 22 июненә барып тоташа.
Яшь кешеләр! Әгәр сез иртә белән ефәк яфраклы гөлләрнең чәчәк атуын күрәсез икән, сез шул иртәдәге өй каршындагы тирәкләрдә кошлар сайравын ишетәсез икән, белегез — бу иртәнге шатлыкта сугышта үлеп калганнарның, фашизм тоткынлыгында үлеп калган солдатларның ялкынлы тормышы бар. Әгәр дә сезнең әбиегез, я әниегез йомшак куллары белән башыгыздан сыйпый икән, үзенең моңлы күзләре белән сезнең күзләрегезгә тутырып карый икән — белегез — ул күзләрдә сугыштан кайтмаган бабаларыгыз һәм әтиләрегез турында тирән сагыш бар. Әгәр сез тыныч өйдә яшисез, иркен мәктәпләрдә укыйсыз, айлы кичтә үзегезнең дусларыгыз белән серләшеп утырасыз икән, белегез — бу җирдә сезнең матур яшәвегез өчен меңләгән солдатларның каны түгелгән. Бу яшьлекнең, бу тормышның кадерен белегез, яшь кешеләр!

1941 нче елның 22 нче июнь таңы.
Бу иртә башка иртәләрдән бер нәрсәсе белән дә аерылып тормый иде. Шул ук сандугач сайрады, кошлар җырлады. Иртән авыл халкы көндәгечә көтүен куды.
Татарстанда бу иртә бәйрәм иртәсе иде. Бәйрәмнең дә ниндие әле. Халыкның ел буе көтеп ала торган, тырыш хезмәттән соң үткәрелә торган сабан туе иде.
Менә шундый тыныч иртәдә илебезнең чигенә дошман бәреп керә. Бөек Ватан сугышы башлана.
Күңел ачарга дип җыелган халык мәйданнан кара кайгы белән таралды. Кич буе юлга әзерләнде. Кем ипиен салды, кем сохариен киптерде, кем юлга биштәрен әзерләде.
Бөтен ил халкы бер булып , дошманга каршы күтәрелде.

Авыл башына чыгып, хатыннар ирләрен, ваемсыз сабыйлар әтиләрен, яшь кызлар сөйгәннәрен фронтка озата. Берни аңламаган сабый сугышның нинди куркыныч икәнлеген белмиләр шул әле.Тиздән, бик тиздән үзләренең ятим каласыннар да, балачаклары буразна арасында үтәсеннәрен дә аңламый алар. Сугыш рәхимсез. “Әткәй, китмә!”- диеп елаган балалар инәлүен дә ишетми ул сугыш.

Сугыш авылдагы һәрбер йортны тетрәтте. Авылда тормыш карт-коры, хатын-кыз, бала-чага кулына күчте. Чәчелгән икмәкне җыеп алырга кирәк иде.

Мондагы тормыш икенче фронтка әйләнде.

Солдат хатыннары! Аларның тормышлары михнәтле, тамаклары ачлы-туклы, күңелләре тулы сагыну иде. Эшенә, ачлыгына түзәр идең, хатыннарны тол, бала-чагаларны ятим итеп авылга туктаусыз кара печатьле кәгазьләр агылды.

Лачын кебек баһадирларыбыз, сугышка киткән хатын-кызларыбыз бер-бер артлы шәһәрләребезне азат иттеләр, Европа илләрен фашистлардан азат итә-итә, Берлингача данлы сугыш юлы үттеләр. Бик күпләре тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп ятып калдылар.

# МУСА ҖӘЛИЛГӘ ИЯРЕП...



1942 нче елның 15 нче феврале. Тиздән 5 яше туласы кызына Муса Җәлил болай дип яза: “Мин синең өчен бик кызыклы әкият уйлап чыгардым.Алтын әтәч турында. Аның артыннан фашистлар куалар, әмма үзләре тозакка килеп эләгәләр” “Ә менә сиңа ышандырган әтәч турында язарга һич вакыт таба алмыйм. Мин аны язармын. Ул-сугыш һәм Әтәч турында бик кызыклы хикәят....”. Әмма Җәлилнең әкияте язылмый кала.
Муса Җәлилгә ияреп.......

## “Алтын Әтәч” әкияте



Авыл бүген дә тынгысыз төн үткәрде... Сугыш гөрелтесе көннән- көн якыная бара. Бу хәл кешеләрнең генә түгел, абзар-курадагы хайваннарның, кош-кортларның да тормышын катлауландырып җибәрде. Алар шарт та шорт иткән тавышка сискәнеп, абзарның бер башыннан икенче башына йөгерештеләр,үзара зарланыша да башладылар. Бу хәлгә бигрәк тә Маһруйбикә әбинең алтын төсле җемелдәп торган әтәче аптырашка калды һәм кызыл кикрикләрен селкетеп уйлана башлады, бер карарга килеп үзенең титиләрен янына чакырды. Бик озак кытаклашкач, бу гөрелтеләрнең азагы хәерле бетмәслегенә төшенделәр һәм Алтын Әтәчне (Маһруйбикә әби яратып аңа шулай дәшә) сәяхәткә, дөнья хәлләрен, гөрелте тавышларының серенә төшенергә чыгарып җибәрделәр.
Шулай бара Алтын Әтәч юл буйлап, вакыты-вакыты белән туктап ял итә, төрле бөҗәкләр белән туклана. Бара торгач аның тамагы кибә, бик каты су эчәсе килә һәм ул якындагы авылга таба юл тота. Ә авылда фашист солдатлары авыз гармунында уйнап ял итеп утыралар. Алтын Әтәч гармун тавышына кушылып “кикирикууууук” дип җырлап җибәрә, фашистлар аптырап карап торалар да, исләренә килеп әтәчне куа башлыйлар. Урам буйлап әтәч чаба, ә аның артыннан шарт та шорт аткалап фашистлар куа. Шулай чаба торгач, биек тау башына килеп җитәләр, ә анда безнең кызыл армия солдатлары фашистларга каршы ут ача. Шунда безнең Алтын Әтәч әкрен генә куак астыннан бу хәлләрне күзәтеп утыра. Гөрелте тавышлары ничек тиз башланса, шулай туктап та кала.
Солдатлар сөенешеп әтәчне күтәреп алалар һәм күкрәкләренә кысалар. Алар әтәч ярдәме белән авылны дошманнардан азат итәләр. Җиңү хисе күңелләрне күтәреп җибәрә. Алтын Әтәч тә кайту юлына борыла, ул тизрәк, туган йортына кайтып, Җиңү турында әйтергә ашыга һәм шуның белән әкият тә бетә.

**САХАПОВА МӘРЬЯМ,3 НЧЕ Г СЫЙНЫФ УКУЧЫСЫ**



# ВИКТОРИНА



1.Бөек Ватан сугышы ничә ел дәвам иткән?
2.Георгий лентасының төсләре нәрсәне аңлата?
3.Фашистлар Германиясен җиңүебез турында радиодан хәбәр итүче дикторның исем фамилиясе ничек?
4.1945 нче елда Җиңү парадын кабул иткән Советлар Союзы маршалының исем фамилиясен атагыз?
5.1945 нче елда Җиңү парадында атлардан башка катнашкан дүрт аяклы сугышчыларны атагыз?
6.Беренче Җиңү парады кайда үткәрелде ?
7.Җиңү парады кайчан үткәрелде һәм ни өчен?
8.Моңа кадәр күрелмәгән Җиңү Салюты кайчан яңгырады?
9.А.Гитлерның ораторлык сәләтеннән башка тагын нинди иҗади сәләтләре бар?
10.Өч елга якын блокадада яшәүче герой шәһәрне атагыз?
11.”Яшәү юлы” (Дорога жизни) нәрсә ул.?
12.Совет солдаты И.Маслов сугышның соңгы көннәрендә сугыш кырыннан кечкенә кызны алып чыга.Кечкенә кызны күтәргән совет солдатына һәйкәл кайсы шәһәрдә тора?
13.Ленинградлылар блокада вакытында өй тәрәзәләрен крест формасында кәгазъ тасмалар белән беркеткәннәр.Ни өчен?
14.Совет самолетларының фюзелажларында төрле төсләр белән ясалган йолдызларны күрергә мөмкин булган.Ул йолдызлар нәрсәне аңлатканнар?
15.Һәйкәл түгел , ләкин сугыш геройларына һәйкәлләр , геройлар каберләре янында урнашкан Бөек Ватан сугышында һәлак булган солдатларга мәңгелек дан символы нәрсә ул?

1. 4 ел.1941-1945
2. Кара төс-төтен,кызылсары төс- утны аңлата
3. Левитан Юрий Борисович.
4. Г.К.Жуков
5. Этләр.
6. Мәскәү.Кызыл мәйдан.
7. 24 июнь 1945 нче елда.Парадта катнашучылар өчен форма тегеп җитештерергә өлгерү өчен.
8. 9 Май 1945 ел
9. А.Гитлерның ораторлык осалыгыннан башка рәсем ясау сәләте көчле булган.Яшь чагында ул сәнгать академиясенә укырга кергән булган.
10. Ленинградта.
11. Яшәү юлы-Ленинград шәһәрен блокада вакытында Зур Җир белән тоташтыручы,Ладога күле аша үтүче магистраль.
12. Берлинда.
13. Бомбёжка вакытында тәрәзәләр ватылмасын өчен.
14. Һава җиңүләре-бәреп төшерелгән дошман самолетлары санын күрсәтә.
15. Мәңгелек ут.







# КОРОНАВИРУСКА КАРШЫ

2019 елның декабрь аенда моңа кадәр кешедә күзәтелмәгән коронавирус штаммы – COVID-19 пәйда булды. Бүгенге көндә коронавирус йөздән артык илгә үтеп керде. КОРОНАВИРУС – кеше һәм хайваннарда сулыш алу әгъзаларын зарарлаучы вирус (атипик үпкә ялкынсынуы (SARS-CoV), Якын Көнчыгыш респирацияле синдромы (*MERS-CoV).*

## АВЫРУ БИЛГЕЛӘРЕ

Коронавирусны эләктереп, 2-14 көн (коронавирусның инкубация чоры) узганнан соң, кешедә бизгәк тоту, ютәл, тән температурасының югары булуы, тын кысылу күзәтелергә мөмкин, болар – зарарлануның төп симптомнары. Шуңа өстәп йөз һәм иреннәр зәңгәрләнеп китсә, күкрәк читлегендә басым, даими авыртулар булса, медицина учреждениесенә мөрәҗәгать итегез. Санап үтелгән һәм башка симптомнарга тап булган очракта да, борчылмагыз. Бу әле сез вирусны йоктыргансыз дигән сүз түгел, әмма табибларга күренеп кайту бер дә комачау итмәс.





### КЕШЕДӘН-КЕШЕГӘ: ВИРУСТАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

Әлегә коронавирусны (COVID-19) кисәтүгә каралган вакцина юк, шуңа күрә вирус белән "элемтәгә кермәү" зарарлануны булдырмауның иң яхшы чарасы булып тора. Вирус кешедән кешегә күчә (авыру кеше ютәлләгәндә яки төчкергәндә таралучы тамчылар икенче кешенең авызына, тын юлларына эләгергә мөмкин – ике кеше арасы 1,8 метрны тәшкил итү дә тыгыз элемтә булып санала).

Өлкән яшьтәгеләр һәм хроник авырулары (йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары, шикәр чире һ.б.) булган кешеләргә сәламәтлекләренә үтә дә игътибарлы булырга кирәк. Алар, вирусны эләктергән очракта, авыруны катлаулырак формада кичерәләр дип санала. Өстәмә чаралар күрү буенча табиб белән элемтәгә керергә киңәш ителә. Әлеге төркем кешеләргә һәм шулай ук башкаларга да:

*** Авырулардан читтәрәк йөрергә;**
*** Кулларны ешрак һәм озаграк сабын белән юарга;**
*** Сәяхәтләрне, очышларны кичектереп торырга киңәш ителә.**

## КОРОНАВИРУС ТУРЫНДА МИФЛАР

Йогышлы авырулар белән беррәттән алар турында хаталы фикерләр дә тарала тора. Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы яңа коронавирус хакында йөргән иң популяр мифларны кире какты:

Коронавирус Кытайдан килгән хатлар һәм посылкалар аша йокмый

Йорт хайваннарың (этләр һәм мәчеләр, мәсәлән) яңа коронавирусны йөртә алуларын дәлилләүче мәгълүмат юк

Үпкә ялкынсынуына (пневмония) каршы вакциналар яңа коронавирустан сакламый, коронавируска каршы вакцина уйлап табу һәм житештерү әлегә галимнәр кулында

Яңа коронавирусны да, башка вирусларны да антибиотиклар белән дәвалап булмый! Вирус бактерияләр китереп чыгара торган авыруларның азып китүенә сәбәпче булган очракта гына – бактерияләргә каршы гына нәтиҗәле булачак.